РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ШЕМОРДАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422050, Республика Татарстан, Сабинский район,
с. Шемордан, ул. Лермонтова, 2
тел. (84362) 3-21-44

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШЭМЭРДЭН АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422050, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Шэмэрдэн авылы Лермонтов урамы, 2 йорт
тел. (84362) 3-21-44

e-mail: Shmd.Sab@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.02.2019 № 10-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Шәмәрдән авыл җирлеге җирле
үзидарә органнарының муниципаль
хезмәткәрләре саны һәм аларның
хезмәт өчен түләүгә факттагы
чыгымнары турында квартал
саен мәгълүматлар бастырып
чыгару тәртибен раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 52 статьясы һәм Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Уставы нигезендә Шәмәрдән авыл җирлеге башкарма комитеты карар итте:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләү буенча факттагы чыгымнары турында квартал саен мәгълүматлар бастырып чыгару тәртибен расларга. (1 нче кушымта ).

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru/shemordan бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Шәмәрдән авыл җирлеге башлыгы: А.Н.Гараев

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 28 февралендә чыккан № 10-п номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәтләре өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында квартал саен мәгълүматлар бастырып чыгару тәртибе.

I. Гомуми нигезләмәләр.

1.1 «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 52 статьясындагы 6 өлеше, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Шәмәрдән авыл җирлеге Уставы нигезендә эшләнгән Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләү чыгымнарының факттагы күрсәткечләрен бастырып чыгару тәртибе (алга таба — Тәртип)

1.2. Тәртип Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында квартал саен белешмәләр тапшыру, раслау һәм рәсми бастырып чыгару процедурасын билгели (алга таба — мәгълүматлар).

II. Авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында мәгълүмат тапшыру тәртибе һәм составы.

2.1. Мәгълүматлар квартал саен җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең уртача саны, шул исәптән хисап чорында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашырган Шәмәрдән авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең исемлек буенча уртача саны турында, шулай ук хисап чорында хезмәт хакына исәпләнгән түләүләрне (акчалата эчтәлек) исәпкә алмыйча, хезмәт өчен түләү чыгымнарын тормышка ашыруга юнәлдерелгән бюджет ассигнованиеләре күләмен чагылдыралар.

2.2. Мәгълүматлар хисап чорыннан соң килүче айның 5 числосына кадәр әлеге Тәртипнең кушымтасы нигезендә бирелә.

2.3 Шәмәрдән авыл җирлеге башкарма комитеты әлеге Тәртипнең кушымтасында бирелгән форма нигезендә мәгълүмат формалаштыра.

III. Җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында квартал саен мәгълүматлар бастырып чыгару тәртибе.

3.1. Шәмәрдән авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан отчет чорыннан соң килүче айның соңгы числосыннан да соңга калмыйча, мәгълүматларны раслау турында Шәмәрдән авыл җирлеге башкарма комитеты карар проекты әзерләнә.

3.1. Шәмәрдән авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән расланган белешмәләр квартал саен хисап артыннан килүче икенче айның соңгы числосына кадәр Шәмәрдән авыл җирлеге сайтында бастырылырга тиеш.

Шәмәрдән авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәтләре өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында квартал саен мәгълүматлар бастырып чыгару тәртибенә кушымта

__________20__ел хисап чорына (беренче квартал, ярты ел, тугыз ай, ел
Шәмәрдән авылҗирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында мәгълүматлар

| Хезмәткәрләркатегориясе | Хисап чоры өчен, хезмәткәрләр саны | Хисап чорына хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнар.<br>(мең сумнарда) |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге муниципаль берәмлеге хезмәткәрләре | | |
| шулисәптән: муниципальхезмәткәрләр | | |